РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.04.2024 Буа шәһәре № 103/Бк-к

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Россия Мәгариф министрлыгының 2023 елның 30 августындагы 642 номерлы боерыгына ярашлы рәвештә, Россия Мәгариф Министрлыгының АБ-3389/10 номерлы хаты, Россия Мәгариф күзәтчелегенең 02-333 номерлы 2022 елның 3 ноябрендәге хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына кабул итү турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 5.1 пункты 1.5.1 пунктчасының түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац белән тулыландырырга:

««Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» 1998 елның 27 маендагы 76-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 8 пунктында күрсәтелгән балаларга һәм «Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре турында» 2016 елның 3 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законның 28,1 статьясында күрсәтелгән балаларга муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында чираттан тыш урыннар бирелә»;

1.2. 2 бүлекнең 5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 2.6.7. пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.6.7. Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье яки Херсон өлкәләре, Украина территорияләреннән килгән балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) гариза бирүченең туганлыгын (яки бала хокукларын тапшыруның законлылыгын) раслаучы документ һәм, әгәр алар Россия Федерациясе гражданнары булмаса, гариза бирүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслаучы документ (миграция картасы һ.б.) күрсәтәләр.

Балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) үз теләкләре буенча башка

документлар, шул исәптән баланың медицина картасын тапшырырга хокуклы.

Документлар рус телендә яки билгеләнгән тәртиптә расланган рус теленә тәрҗемә белән бергә тапшырыла.

Шул ук вакытта рус телендә документлар булмау яки аларның рус теленә расланган тәрҗемәсе гомуми белем бирү оешмасына кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

Гадәттән тыш хәлләр аркасында ата-аналар (законлы вәкилләр) белем бирү оешмасына кабул итү өчен кирәкле документларны тапшыра алмаган очракта, баланы ата-ананың (законлы вәкилнең) гаризасы нигезендә кабул итәргә киңәш ителә.

Аерым очракларда (әгәр бала Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье яки Херсон өлкәләре, Украина территорияләреннән конкрет бала мәнфәгатьләрен якларга законлы хокукы булмаган туганы яки башка зат озата килгән булса, яки озата килмичә) баланы белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмага туганының яки баланың гомуми белем алу хокукын тәэмин итүдә кызыксынучы башка кешенең гаризасы нигезендә яки 14 яшькә җиткән баланың шәхси гаризасы нигезендә кабул итәргә кирәк.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында рәсми рәвештә басылып чыккан көннән башлап законлы көченә керә http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылырга тиеш http://buinsk.tatarstan.ru/

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары –«Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Н.А. Македонскаяга йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов